**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 16 июнь № 409

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика эвакуация комиссиясе турындагы нигезләмәне һәм аның составын раслау турында» 2006 ел, 26 июнь, 323 нче карары белән расланган Республика эвакуация комиссиясе хакындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика эвакуация комиссиясе турындагы нигезләмәне һәм аның составын раслау турында» 2006 ел, 26 июнь, 323 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 8 май, 299 нчы; 2010 ел, 8 июнь, 447 нче; 2012 ел, 29 февраль, 169 нчы; 2013 ел, 6 март, 148 нче; 2016 ел, 29 февраль, 122 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Республика эвакуация комиссиясе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1 пунктның алтынчы абзацын төшереп калдырырга;

2.1 пунктның җиденче абзацында, 2.2 пунктның унынчы, уникенче абзацларында, 2.3 пунктның алтынчы абзацында, 6.3 пунктның өченче, бишенче, алтынчы абзацларында, 6.4 пунктның алтынчы абзацында, 6.6 пунктның өченче абзацында тиешле килешләрдәге «шәһәр чите зонасы» сүзләрен тиешле килешләрдәге «куркынычсыз районнар» сүзләренә алмаштырырга;

2.2 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гадәттән тыш хәлләр барлыкка килгәндә яки гражданнар оборонасы буенча өченче чираттагы беренче чиратлы чаралар башкарганда Комиссия:»;

6.3 пунктның сигезенче абзацында «көчсез» сүзен төшереп калдырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков